МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.10.2021 г.Казань № 784

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 17 ноябрендә 8115 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 25 октябрендәге 784 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 14 апрелендәге 231 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.06.2017 №416, 07.05.2018 №348, 15.05.2018 №365, 18.09.2018 №858, 24.06.2019 №494, 11.11.2019 №978, 01.06.2020 №380, 09.10.2020 №718, 04.06.2021 №395 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлекчәсенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган. Айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктның 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);»;

1.6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү (алга таба – компенсация)

2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча;

телефонга смс-хәбәр итеп.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү

гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгәннән соң ун көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләп бетергәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк булмаган чорга гына.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү), әлеге Регламентның 2.4.2 пунктчасы нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чорын исәпкә алмыйча, компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында белдерү алган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны шәхсән бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1. Банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган хосусый счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча компенсация билгеләү турында гариза.

2. Дәвалану урынына килү һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын раслаучы документлар (булган очракта), түбәндәге транспорт төрләрендә:

тимер юл транспорты (барлык категориядәге поездлар һәм вагоннар, фирмалы поездлардан һәм югары уңайлыклы вагоннардан тыш);

су транспорты (III категорияле);

шәһәрара һәм шәһәр яны билгеләнешендәге (уртак файдаланудагы) автомобиль транспорты;

тимер юл булмаганда авиация транспорты (эконом класс).

3. Гариза биргән айдан алда килүче 3 айда гаиләнең һәр әгъзасы тарафыннан акчалата һәм натураль формада алынган керемнәр турында документлар, шул исәптән:

отставкага киткән судьяларга гомер буе ай саен түләнә тәэминат күләме турында белешмә;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучыюгары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән

категорияләренә компенсация түләүләре күләме турында белешмә;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесенең бәяләмәсе буенча аларның балалары 18 яшенә җиткәнче читләрнең каравына мохтаҗ булса, ирнең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда ай саен түләнә торган пособие күләме турында белешмә;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләүләре күләме турында белешмә;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарның хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә азык-төлек тәэминаты күләме турында белешмә;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнарыннан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнардан эштән киткәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие күләме турында белешмә;

гаилә әгъзалары ала торган алиментлар күләме турында белешмә.

4. Мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән (ялгыз яшәүче гражданиннан кала) ирекле формада документ (документлар), түбәндәгеләрне раслаучы:

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.

5. Ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе.

2.5.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.4. Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

2.5.5. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законндагы (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге белешмәләр алына:

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары ала торган пенсия һәм башка социаль түләүләрнең күләме турында;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан алынган керемнәр турында;

гражданин тарафыннан дәвалану чоры турында (Татарстан Республикасы медицина оешмасында);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы турында (вәкаләтле оешмаларда).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.2. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1. Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве.

2. Күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) төп документларның күрсәтелмәве.

3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүченең төгәл булмаган белешмәләрне һәм документларны тапшыру;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы, компенсация билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган булса.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Гариза һәм документлар кергән көннән башлап бер көн эчендә

2.13.2. Гариза һәм кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар исемлегенә карата таләпләр. Шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата да

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының икенче абзацында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктал ы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтү мөмкинлегенең булуы яки булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

бүлекчә бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.15.3. мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык (http://mtsz.tatarstan.ru) сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

2.16.1. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законндагы (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 нче бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ

процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, вәкаләтле органнарга түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

гражданин тарафыннан дәвалану узу чоры турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары ала торган пенсия һәм башка социаль түләүләрнең күләме турында;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан алынган керемнәр турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вәкаләтле органнарга җибәрелгән мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлекчәсе белгече компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан компенсация билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны бирә.

Әлеге пунктта каралган процедураларны үтәү срогы:

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында белдерү әлеге пункт нигезендә җибәрелгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында белдерү; мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать итүче шәхсән

мөрәҗәгать иткән очракта, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар бирү.»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә

_______________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА №____

Дата: «____» ____________ 20___ ел.

Мин,______________________________________________________________,

(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), тулысынча)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафын | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | нан бирелгән | |
| | | | |

яши торган адрес: ________________________________________________,
______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефон номеры, электрон почта адресы)
эш итү нигезе:
______________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________

Билгеләвегезне сорыйм ____________________________________________,
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), тулысынча)

яши торган адрес: ________________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
______________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

| №т/с | Социаль ярдәм чаралары | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|---|
| 1 | амбулатор гемодиализ ысулы белән дәваланучы хроник бөер җитешсезлегеннән интегүче затларга амбулатор гемодиализ узу урынына транспортта бару чыгымнарын һәм яшәү урынына кайту чыгымнарын компенсацияләү | |
| 2 | онкология авыруларыннан интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының махсуслаштырылган онкологик ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта йөрү чыгымнарын һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү | |

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |

| | | |
|---|---|---|
| 4 | | |

Компенсация алучы затның гаилә составы:

| № | | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) (туган көне) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |

Билгеләнгән компенсацияне түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:
әлеге счетка күчерү юлы белән ________________________________________
(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)
почта бүлекчәсе аша ____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ______________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затның имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, риза:
почта адресы буенча язма формада __________________________________________
____________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча _______________________
(электрон почта адресы)
Мөрәҗәгать итүче яисә аның мәнфәгатьләрендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат:
____________________________________________ _______ «__»________ 20_ ел.
(гариза бирүченең яисә гариза бирүче мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә белдерүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (имза)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел.

_________ ____________________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

___________________________________________________________________________.

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры _________________

Документлар саны ___ берәмлек, ___ биттә

Документларны кабул итте ___________ _________ _____________________ _____________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе

____________________________________

____________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль ярдәм чараларын билгеләү (бирү) турында карар

№_____ «____» ____________

Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) ________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы ________________________________________

Билгеләргә (бирергә):

| | | Түләү | Билгеләнү | Түләү вакыты: |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | амбулатор гемодиализ ысулы белән дәваланучы хроник бөер җитешсезлегеннән интегүче затларга амбулатор гемодиализ узу урынына транспортта бару чыгымнарын һәм яшәү урынына кайту чыгымнарын компенсацияләү | | | |
| | онкология авыруларыннан интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының махсуслаштырылган онкологик ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта йөрү чыгымнарын һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү | | | |

Компенсацияне түләү ысулы ________________________________________
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе

____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ____________________________ ______________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))
(имза)
Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече

____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ____________________________ ______________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
әлеге адрес буенча язмача формада______________________________________
________________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресына ________________________________________
(электрон почта адресы)
бүлек белгече ____________________________ ______________

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №____ бүлекчәсе
___________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль ярдәм чаралары билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турында карар

№_______ «____» ____________

Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) ________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ________________________________________
___________________________ билгеләүдән (бирүдән) баш тартырга
(түләүнең аталышы)
Баш тарту сәбәбе: _______________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе
_______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) _________________________ ____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)
Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече
_______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) _________________________ ____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)
Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
әлеге адрес буенча язмача формада__________________________________
___________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча _________________________
(электрон почта адресы)
бүлек белгече _________________________ ____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2018 №703, 18.09.2018

№885, 24.06.2019 №494, 17.10.2019 №853, 09.04.2020 №238, 14.07.2020 №516, 09.10.2020 №717, 19.03.2021 №150 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлекчәсенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган. Теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалану өчен бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарын каплау өчен субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм контрольлек башкаручы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турындагы белешмәләр әлеге Регламентның белешмә кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктның 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);»;

1.5 пунктта «норматив-хокукый» сүзләрен «норматив хокукый» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Даими рәвештә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда яши торган хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү (алга таба – бер тапкыр түләү).

2.2. Дәүләт хакимияте органы исеме

Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча;

телефонга смс-хәбәр итеп.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар барлык кирәкле документлар белән бер мәртәбә түләү билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) бер мәртәбә түләнә торган түләү бирү (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көндә гамәлгә ашырыла.

Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында белдерү алган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны шәхсән бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында гариза;

2) баланың (балаларның) тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

3) чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән ананың үлеме турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

4) Татарстан Республикасы территориясендә кимендә өч ел даими яшәү фактын билгеләү турында законлы көченә кергән суд карары күчермәсе – гариза белән мөрәҗәгать иткән датага кимендә өч ел дәвамында Татарстан Республикасы террито-

риясендә авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокта яшәү урыны буенча теркәлү булмаган очракта;

5) вәкаләтле затлар өчен ышаныч кәгазе күчермәсе.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.5.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.5.3. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.5. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закондагы (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.

### 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге белешмәләр алына:

бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

ананың (атаның) вафат булуын дәүләт теркәвенә алу турында;

опека (попечительлек) билгеләнүе турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

әлеге Регламентның 2.5 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очрактан

тыш, Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими, кимендә өч ел яшәү фактын раслый торган;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында;

шәхси счетның иминият номеры турында.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.5. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

2) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

3) документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы;

4) күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве;

5) Үзәк бүлекчәсенә электрон документлар формасында электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) тапшыру;

6) мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып, булган мәгълүматлар һәм (яки) документлар нигезендә, аны алу хокукының булмавы тора.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан

артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Гариза һәм документлар кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар исемлегенә карата таләпләр. Шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата да

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының икенче абзацында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать)

тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтү мөмкинлегенең булуы яки булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үзәк бүлекчәләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

хезмәткәрләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итела торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.15.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык (http://mtsz.tatarstan.ru) сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлекчәсе белгече бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан бер тапкыр түләү билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны бирә.

Әлеге пунктта каралган процедураларны үтәү срогы:

бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү бер тапкыр түләү бирү (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында белдерү әлеге пункт нигезендә җибәрелгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында белдерү; мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, бер тапкыр түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар бирү.»;

5 бүлектә:

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе;

5.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә яки Министрлыкка кергән шикаять алынган көненнән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яши торган хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА №____

Дата: «____» ____________ 20___ ел.

Мин,

_____________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

яши торган адрес:

_____________________________________________________________________,

(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

эш итү нигезе:

_____________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры ______________

Билгеләвегезне сорыйм ______________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта)

яши торган адрес: _______________________________________________________
_______________________________________________________________________.
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
_______________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яши торган хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү турында» 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карары нигезендә

_________________________________ бала туганда бер бирелә торган түләү
(беренче (икенче һәм аннан соңгы һәр туган)

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Түләү алучы затның гаилә составы:

| № | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) ________________________ ________, (туган көне) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында булмавын раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата
_______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукында чикләнмәгән

_____________ ___________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________

(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Билгеләнгән түләүне түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:

әлеге счетка күчерү юлы белән ______________________________________

(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым _________________________

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, риза:

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп __________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресы буенча __________________________

(электрон почта адресы)

Мөрәҗәгать итүче:_________________________ _________ «__»______ 20__ ел.

(мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел.

_________ ____________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ____

Документлар саны ___ берәмлек, ___ биттә

Документларны кабул итте ___________ _________ __________ ______________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яши торган хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе
______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

№________ _________ 20__ ел.

Бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү (бирү) турында карар

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
____________________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы: ______________________________________________

Балага ______________________________________________________________
(Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Шәхси счет реквизитлары: __________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ______________________________ ____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе хезмәткәре
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ______________________________ __________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр螺 ителде:

элеге адрес буенча язмача формада,
_________________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ______________________________
(электрон почта адресы)

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе
______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

№________ _________ 20__ ел.

Бала туганда бер тапкыр түләү билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турында карар

Баш тартырга ____________________________________________________________,
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адресы _______________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең адресы)
бала туганда бер тапкыр түләү билгеләүдән (бирүдән) ___________________________
______________________________________________________________________
(Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Баш тарту сәбәбе: _______________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе
_____________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)
_____________________________ ____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе хезмәткәре
_____________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)
_____________________________ ______________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
әлеге адрес буенча язмача формада,
_______________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ____________________________
(электрон почта адресы)».